2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авылы җирлеге Яңа Никольский авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

1 ноябрь 2025 ел № 12

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең Яңа Никольский авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең Яңа Никольский авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Кечләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт тезегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту: (юлларга вак таш җәю).

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Яңа Никольский авылы, Үзәк урамы, 100 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Никольский авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Фазлыев

НОВОНИКОЛЬСКИЙ СЕЛЬСКИЙ СОВЕТ